Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

24 июнь 2019 ел №296

Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазифаларын биләүгә конкурс игълан итү турында

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату сәбәпле, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставының 29, 46 статьяларына, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына таянып,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2015 елның 23 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс игълан итү турында» 6 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (1 нче кушымта);

2.2. Карарның 2 пунктының 2 нче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

2.3. Карарның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссиясе әгъзаларын билгеләргә» (2 нче кушымта);

2.4. Карарның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурсны 2019 елның 26 июленә кадәр үткәрергә, конкурс нәтиҗәләрен һәм кандидатлар турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советына тәкъдим итәргә».

3. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Баһманов И.Р.).

Муниципаль район
башлыгы урынбасары А.А. Зимин

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Советының 2019 елның
24 июнендәге 296 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты
Җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Әлеге Нигезләмә белән «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы нигезендә Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе һәм шартлары билгеләнә (алга таба – башкарма комитет җитәкчесе).

2. Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазифаларын биләүгә конкурсның төп максаты – Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты (Алга таба–башкарма комитет) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү, һөнәри, эшлекле һәм әхлакый сыйфат буенча кадрлар сайлау һәм урнаштыру сыйфатын яхшырту, аларның инициативаларына, идарә һәм методик эшне камилләштерүгә омтылышларына стимул бирү.

3. Конкурсны үткәрү өчен Әлмәт муниципаль районы Советы тарафыннан (алга таба – Совет) конкурс комиссиясе төзелә. Конкурс комиссиясе составы, аның эшләү вакыты һәм тәртибе әлеге Нигезләмә белән билгеләнә.

4. Конкурс комиссиясе 6 кешедән тора.

5. Конкурс комиссиясе формалаштырганда аның әгъзаларының яртысы Совет, ә икенче яртысы - Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.

6. Конкурс комиссиясенең рәисе, урынбасары һәм секретаре Совет тарафыннан раслана.

7. Конкурс Совет карары буенча игълан ителә.

8. Конкурс түбәндәге шартларда үткәрелә:

1) кандидатның башкарма комитет җитәкчесе вазифасына алынуы өчен шарт:

а) Россия Федерациясе гражданины булуы;

б) тиешле эшчәнлек юнәлешенә туры килә торган югары белеме булу;

в) муниципаль хезмәт яки белгечлек буенча кимендә ике ел, юнәлеш буенча кимендә дүрт ел эш стажы;

г) идарә эшчәнлеге тәҗрибәсе кимендә биш ел. Идарә эшчәнлеге дигәндә, оешма җитәкчесе урынбасары, дәүләт органы, муниципаль орган, шулай ук аларның структур бүлекчәләре җитәкчеләре вазифаларындагы эш күздә тотыла.

д) башкарма комитет җитәкчесе вазифаларын башкару өчен кирәкле күләмдә түбәндәге эшлекле сыйфатлар һәм күнекмәләр:

- Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, федераль законнарны һәм Татарстан Республикасы законнарын, Әлмәт муниципаль районы Уставын һәм башка муниципаль хокукый актларны белүне дә кертеп, аның компетенциясендә булган мәсьәләләр дә җайга салу һәм башкарма комитетны алып бару өчен;

- Әлмәт муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен һәм аңа йөкләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча башкарма комитетның эшчәнлек

юнәлешләрен билгеләү, бу эшчәнлекнең яңа формаларын һәм ысулларын табу, аларны гамәли тормышка ашыру механизмнарын эшләү сәләте;

- үз эшчәнлеген планлаштыру, оештыру һәм анализлау, башкарма комитет, аның органнары һәм башкарма комитет җитәкчесенә буйсынган хезмәткәрләрнең эшчәнлеге;

- этик нормаларны белү һәм аларны хезмәт аралашуында куллана белү;

2) кандидатның муниципаль хезмәткә керү һәм аны узу өчен муниципаль хезмәт турындагы законнарда билгеләнгән чикләүләрнең булмавы.

9. Район башкарма комитеты җитәкчесе вазифасына конкурс үткәрү һәм конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында хәбәр «Альметьевский вестник» газетасында басылып чыга һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырыла.

10. Конкурс үткәрү турында хәбәрдә күрсәтелә:

1) вазифаның тулы исеме;

2) әлеге вазифаны биләп торуга дәгъва кылучыга карата куелган таләпләрне үз эченә алган конкурсны үткәрү шартлары;

3) бәйгене үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

4) әлеге Нигезләмәнең 12 пункты нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны, вакыты һәм күрсәтелгән документларны кабул итү срогы;

5) башкарма комитет җитәкчесе белән төзелә торган контракт проекты;

6) конкурс турында тулы мәгълүмат турында мәгълүматлар (телефон, факс, электрон почта, электрон адрес).

11. Конкурс үткәрү турында хәбәр конкурсны үткәрү көненә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча басыла.

12. Конкурста катнашырга теләгән затлар конкурс комиссиясенә гариза бирәләр, аңарга түбәндәге документлар теркәлергә тиеш:

1) шәхси гариза;

2) әлеге Нигезләмәнең кушымтасы нигезендә үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета, 4 х 6 үлчәмендәге фоторәсемнәр һәм автобиография;

3) паспорт күчермәсе (паспорт конкурска килгәндә шәхсән күрсәтелә);

4) югары белем, эш стажы һәм квалификациясе булуын раслаучы документлар:

- гражданинның хезмәт (хезмәт) эшчәнлеген раслый торган хезмәт кенәгәсенең яисә башка документларның төп нөсхәсе һәм күчермәсе;

- һөнәри белем турындагы документларның төп нөсхәсе һәм күчермәсе, шулай ук, гражданин теләге буенча, нотариаль яки кадрлар хезмәтләре тарафыннан эш урыны буенча расланган (хезмәт итү) өстәмә һөнәри белем бирү, гыйльми дәрәҗә бирү, гыйльми исем бирү турындагы документлар;

5) мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, муниципаль хезмәткә кергән еллар өчен;

6) муниципаль хезмәткә керүгә комачаулаучы авыруның булмавы турында медицина оешмасы бәяләмәсе;

Конкурсант аның профессиональ әзерлеген характерлаучы башка документларны тәкъдим итә ала.

13. Гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар махсус журналда, тәртип теркәү номеры бирелү белән теркәлә.

Гариза биргән затка алынган документлар исемлеген һәм датасын күрсәтеп, расписка бирелә.

14. Тапшырыла торган документларны кабул итү һәм тикшерү конкурс комиссиясе секретаре тарафыннан башкарыла. Документларның төп нөсхәләре

гариза бирүчегә аларны тәкъдим иткән көнне кире кайтарыла, ә күрсәтелгән документларның күчермәләре делога теркәлә.

15. Әлеге Нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгән документлар конкурс комиссиясенә конкурс үткәрү турында хәбәр басылып чыккан көннән алып 20 көн эчендә тапшырыла.

Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып күрсәтү гражданинга аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

16. Конкурс гариза бирү вакыты тәмамланганнан соң 10 көн эчендә үткәрелә.

17. Конкурс башкарма комитет җитәкчесе вазифасын биләүгә кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның әлеге вазифага квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

18. Тапшырылган документлар нигезендә конкурс комиссиясе конкурста катнашуга мөмкинлек алган кандидатлар турында карар кабул итә.

19. Гражданның конкурста катнашуга кертелмәве башкарма комитет җитәкчесе вазифасына квалификация таләпләренә туры килмәү, шулай ук муниципаль хезмәткә керү һәм аны узу өчен муниципаль хезмәт турындагы законнар белән билгеләнгән чикләүләр белән бәйле рәвештә рөхсәт ителми.

Конкурста катнашырырга рөхсәт ителмәгәндә, гражданин әлеге карарга карата суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

20. Конкурс комиссиясе кандидатларны үзләре тәкъдим иткән белем, башка дәүләт һәм муниципаль хезмәт узу, үз программалары, башка хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру турындагы документлар нигезендә, шулай ук шәхси әңгәмә вакытында, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килмәгән кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларын кулланып конкурс процедуралары нигезендә бәяли.

21. Кандидатларны тикшерү һәм сайлап алу конкурс комиссиясе утырышларында гамәлгә ашырыла.

Конкурс комиссиясе утырышы әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында билгеләнгән конкурс комиссиясе әгъзалары саныннан кимендә өчтән икесе катнашса хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе карарлары әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында билгеләнгән комиссия әгъзалары санының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

22. Конкурс комиссиясе карары кандидат катнашыннан башка кабул ителә.

23. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре карар белән рәсмиләштерелә, ул утырышта катнашкан конкурс комиссиясе рәисе, секретаре һәм әгъзалары тарафыннан имзалана.

24. Конкурс нәтиҗәләре һәм кандидатлар турында мәгълүмат конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан конкурс тәмамланганнан соң өч көн эчендә Советка тапшырыла.

25. Конкурс комиссиясе сайлап алу нәтиҗәләре буенча дәгъва кылучылар арасыннан башкарма комитет җитәкчесе вазифасына кимендә ике кандидат тәкъдим итә.

26. Әгәр конкурс үткәрү нәтиҗәсендә башкарма комитет җитәкчесе вазифасы квалификациясе таләпләренә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаса, конкурс комиссиясе тәкъдиме буенча Совет кабат конкурс үткәрү турында карар кабул итә.

Кабат конкурс үткәрү турындагы карар Совет тарафыннан, шулай ук, конкурс комиссиясе тәкъдим иткән кандидатлар башкарма комитет җитәкчесе вазифасына билгеләп кую өчен кирәкле тавыш җыймаган очракта да кабул ителә.

27. Конкурс комиссиясе конкурста катнашкан кандидатларга конкурс нәтиҗәләре турында аны тәмамлау көненнән өч көн эчендә язма рәвештә хәбәр итә.

28. Башкарма комитет җитәкчесе вазифасын биләүгә дәгъва итеп конкурста катнашуга кертелмәгән һәм конкурста катнашучы кандидатларның документлары конкурс тәмамланганнан соң өч ел эчендә, язма гариза буенча кире кайтарылырга мөмкин. Әлеге срок тәмамланганчы документлар Советта саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш.

29. Конкурста катнашу белән бәйле чыгымнар (конкурс үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урынын наемга алу, яшәү, элемтә чараларыннан файдалану һәм башкалар) кандидатлар тарафыннан үз акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Муниципаль район
башлыгы урынбасары А.А. Зимин

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Советының
2019 елның 24 июнендәге
296 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты
Җитәкчесе вазифасын биләүгә кандидатураларны карау өчен
конкурс комиссиясе составы

| № | Ф. И. О. | Эш урыны, вазифасы | Кем тарафыннан билгеләнгән | Комиссия составындагы статус |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Әфләтунова Роза Егоровна | Әлмәт муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе | Әлмәт муниципаль районы Советы | Комиссия рәисе |
| 2. | Баһманов Илдар Рәис улы | Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты, законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссия рәисе | Әлмәт муниципаль районы Советы | Комиссия әгъзасы |
| 3. | Ханнанова Әлфия Бәшир кызы | Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының хокук идарәсе җитәкчесе | Әлмәт муниципаль районы Советы | Комиссия секретаре |

Муниципаль район
башлыгы урынбасары А.А. Зимин